СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

23.04.2021 № 9/7

На № ________ от ________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясы 1 өлеше нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетын административ комиссия төзүгә вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

2. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләргә:
- административ комиссия төзергә;
- административ комиссия составын расларга;
- административ комиссиянең эш регламентын расларга.

3. Тукай муниципаль районы Советының 2007 елның 19 декабрендәге «Тукай муниципаль районының административ комиссиясе турында нигезләмә хакында» 19/4 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарны муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе — Ф.М. Камаев